КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2023 ел, 2 март г.Казань № б-544

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 28 гыйнвар, б-136 нчы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру чаралары комплексын гамәлгә ашыру кысаларында:»;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча чаралар комплексын гамәлгә ашыруны мониторинглауны һәм контрольдә тотуны гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы нигезләмәнең 7 пунктындагы икенче абзацында «квартал» сүзен «ел» сүзенә алмаштырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакытлы карау системасын булдыру чаралары комплексын тормышка ашыруны мониторинглауны һәм тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру буенча ведомствоара эшче төркем составында:

Фердинат Равил улы Закировның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе урынбасары (килешү буенча)»;

Елена Петровна Поляکованың вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының Татарстан Республикасы буенча бүлеге идарәчесе урынбасары (килешү буенча).».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин